**Казан шәһәре Башкарма комитетының
2025 елның 12 ноябрендәге 3914 номерлы карары**

**2026 елга Казан шәһәренең мәктәпкәчә белем бирү
мәгариф программасын гамәлгә ашыра торган
мәктәпкәчә белем бирү оешмаларына йөрүче
балалары булган гражданнарга
социаль ярдәм чараларын күрсәтү турында**

Казан шәһәре Башкарма комитетының 2021 елның 28 декабрендәге 3492 номерлы карары белән расланган «2022-2026 елларга Казан шәһәрендә мәгарифне үстерү» муниципаль программасын гамәлгә ашыру кысаларында һәм Казан шәһәренең мәктәпкәчә белем бирү мәгариф программасын гамәлгә ашыра торган мәктәпкәчә белем бирү оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чараларын күрсәтү максатыннан **карар бирәм**:

1. 2026 елның 1 гыйнварыннан башлап түбәндәге төркемнәргә йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләрен билгеләргә:

1.1. Казан шәһәренең муниципаль мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренә һәм Казан шәһәренең гомуми белем бирү учреждениеләрендәге мәктәпкәчә төркемнәргә;

1.2. Казан шәһәренең мәктәпкәчә белем бирү мәгариф программасын гамәлгә ашыра торган, вәкаләтле орган белән тиешле килешүләр төзегән шәхси белем бирү учреждениеләрендәге муниципаль төркемнәргә.

Муниципаль төркем дигәндә «Электрон балалар бакчасы» автоматлаштырылган мәгълүмат системасы аша мәктәпкәчә белем бирү мәгариф программасын гамәлгә ашыра торган шәхси белем бирү учреждениесенә юлланган балалар төркеме аңлашыла.

2. 2026 елга Казан шәһәренең мәктәпкәчә белем бирү мәгариф программасын гамәлгә ашыра торган муниципаль мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренә һәм Казан шәһәренең гомуми белем бирү

учреждениеләрендәге мәктәпкәчә төркемнәргә, шулай ук Казан шәһәренең шәхси белем бирү учреждениеләрендәге муниципаль төркемнәргә йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләрен бирү тәртибен (алга таба − Тәртип) әлеге карарның кушымтасы нигезендә расларга.

3. Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсен Казан шәһәренең мәктәпкәчә белем бирү мәгариф программасын гамәлгә ашыра торган муниципаль мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренә һәм Казан шәһәренең гомуми белем бирү учреждениеләрендәге мәктәпкәчә төркемнәргә, шулай ук Казан шәһәренең шәхси белем бирү учреждениеләрендәге муниципаль төркемнәргә йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләү функцияләрен гамәлгә ашыруга вәкаләтле орган итеп билгеләргә.

4. Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсенә (И.А.Ризванов):

4.1. Казан шәһәренең мәктәпкәчә белем бирү мәгариф программасын гамәлгә ашыра торган муниципаль мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренә һәм Казан шәһәренең гомуми белем бирү учреждениеләрендәге мәктәпкәчә төркемнәргә, шулай ук Казан шәһәренең шәхси белем бирү учреждениеләрендәге муниципаль төркемнәргә йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләрен бирүне расланган Тәртип нигезендә гамәлгә ашырырга;

4.2. законнар нигезендә консультация хезмәтләрен күрсәтү, документлар җыю һәм кабул итү, компенсацияне исәпләү һәм билгеләү чараларын уздыруны Казан шәһәренең мәктәпкәчә белем бирү мәгариф программасын гамәлгә ашыра торган муниципаль мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренә һәм Казан шәһәренең гомуми белем бирү учреждениеләрендәге мәктәпкәчә төркемнәргә, шулай ук Казан шәһәренең шәхси белем бирү учреждениеләрендәге муниципаль төркемнәргә йөрүче балалары булган гражданнарны кабул итү, консультация бирү, компенсация билгеләү (компенсация билгеләүдән баш тарту) турында карар кабул итү хезмәтләрен күрсәтүгә килешү төзелгән махсуслаштырылган оешма аша башкарырга.

5. Казан шәһәренең мәктәпкәчә белем бирү мәгариф программасын гамәлгә ашыра торган муниципаль мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренә һәм Казан шәһәренең гомуми белем бирү учреждениеләрендәге мәктәпкәчә төркемнәргә, шулай ук Казан шәһәренең шәхси белем бирү учреждениеләрендәге муниципаль төркемнәргә йөрүче балалары булган гражданнарга түләүләр 2026 елда әлеге максатларга Казан шәһәренең җыелма

бюджет исемлегендә каралган акча чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

6. Әлеге карар 2026 елның 1 гыйнварыннан гамәлгә керә дип билгеләргә.

7. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 20 декабрендәге 5257 номерлы «2025 елга мәктәпкәчә белем бирү мәгариф программасын гамәлгә ашыра торган Казан шәһәренең мәктәпкәчә белем бирү оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чараларын күрсәтү турында»гы карарын гамәлдән чыккан дип танырга.

8. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

9. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары А.И.Абзаловка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2025 елның 12 ноябрендәге
3914 номерлы карары белән
расланды

**2026 елга Казан шәһәренең мәктәпкәчә белем бирү мәгариф программасын гамәлгә ашыра торган муниципаль мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренә һәм Казан шәһәренең гомуми белем бирү учреждениеләрендәге мәктәпкәчә төркемнәргә, шулай ук Казан шәһәренең шәхси белем бирү учреждениеләрендәге муниципаль төркемнәргә йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләрен бирү тәртибе**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Тәртип Казан шәһәренең мәктәпкәчә белем бирү мәгариф программасын гамәлгә ашыра торган муниципаль мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренә һәм Казан шәһәренең гомуми белем бирү учреждениеләрендәге мәктәпкәчә төркемнәргә, шулай ук Казан шәһәренең шәхси белем бирү учреждениеләрендәге муниципаль төркемнәргә (алга таба – балалар бакчалары) йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация билгеләү һәм түләү механизмын билгели.

1.2. Компенсация балалар бакчасы белән килешү төзегән һәм мәктәпкәчә белем бирү мәгариф программасын гамәлгә ашыра торган тиешле мәктәпкәчә белем бирү учреждениесендә баланы карау һәм тәрбияләү өчен ата-аналар түләвен керткән законлы вәкилгә (ата-анага, тәрбиягә алучыга, опекунга) яки аның вәкаләтле затына (алга таба – гариза бирүче) гаиләнең җан башына уртача керемен исәпкә алып билгеләнә һәм түләнә.

1.3. Компенсация алу хокукын билгеләгәндә, гаиләнең җан башына уртача кереме Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 3 декабрендәге 1095 номерлы «Өч яшькә кадәрге балалары булган гаиләләргә дарулар сатып алуга түләү турында»гы карары белән билгеләнгән кагыйдәләр буенча исәпләнә.

Компенсация билгеләү өчен гаиләнең җан башына уртача кереме барлык кирәкле документлар белән компенсацияне билгеләү турында гариза тапшырылган айга кадәр килә торган соңгы 12 календарь ай (алга таба – исәпләү

чоры) өчен билгеләнә.

Исәпләү чорында гаиләнең җан башына уртача кереме гаиләнең уртача айлык җыелма керемен гаилә әгъзалары санына бүлү юлы белән исәпләнә.

Исәпләү чорында гаиләнең уртача айлык җыелма кереме гаиләнең барлык әгъзаларының уртача айлык керемнәре суммасына тигез.

Гаиләнең һәр әгъзасының уртача айлык кереме аның исәпләү чорында алынган керемнәре суммасын әлеге керемнәр алынган шушы исәпләү чорындагы айлар санына бүлү юлы белән билгеләнә.

1.4. Компенсация күләмен билгеләгәндә, гаилә составында түбәндәгеләр исәпкә алына:

- тәрбиядә булган һәм 18 яше тулмаган, шул исәптән хастаханәләрдә, балалар шифаханәләрендә дәвалануда булган балалар, шулай ук мәктәп-интернатларда яшәгән өчен ата-аналары өлешчә түләп тора торган балалар;

- ата-аналары белән бергә яшәү-яшәмәвенә бәйсез рәвештә, 18 яшьтән 23 яшькәчә булган (гаилә корып яшәми торган), укытуның көндезге формасы буенча, шул исәптән дәүләтнеке булмаган белем бирү учреждениеләрендә белем алучы балалар;

- башка ата-ана гаиләсендә исәпкә алынмаган булсалар, гаиләдә яшәүче үги уллар һәм үги кызлар;

- гражданнарның гаиләләрендә опекага алынган балалар;

- тәрбиягә бала алган гаиләләрдә тәрбияләнә торган балалар.

1.5. Гаилә составына түбәндәге балалар кертелми:

- ата-анасының икесе дә (тулы булмаган гаиләдә – берсе) ата-ана хокукыннан мәхрүм ителгән булсалар;

- тулысынча дәүләт тәэминатында булганнар.

1.6. Компенсация күләме түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$ДК = Ф \times (100\text{-}МДД) – К,$$ биредә:

ДК – компенсация күләме;

Ф – мәктәпкәчә белем бирү мәгариф программасын гамәлгә ашыра торган белем бирү оешмасында баланы карау һәм тәрбияләү өчен тиешле елга Казан шәһәре Башкарма комитеты карары белән расланган ата-аналарның түләү күләме чикләрендә фактта алына торган, ата-ана тарафыннан кертелгән түләү күләме;

МДД – мәктәпкәчә белем бирү мәгариф программасын гамәлгә ашыра торган белем бирү оешмасында баланы карау һәм тәрбияләү өчен гражданнарның ата-аналар түләвенә киткән чыгымнарының максималь мөмкин булган, таблица нигезендә билгеләнә торган өлеше;

К – мәктәпкәчә белем бирү мәгариф программасын гамәлгә ашыра торган белем бирү оешмасында баланы карау һәм тәрбияләү өчен ата-аналар түләвенең бер өлешен компенсацияләүнең Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 гыйнварындагы 9 номерлы «Мәктәпкәчә белем бирү мәгариф программасын гамәлгә ашыра торган белем бирү оешмаларында баланы карау һәм тәрбияләү өчен ата-аналар түләвенең бер өлешен компенсацияләү турында»гы карары белән билгеләнгән тәртиптә исәпләнгән күләме.

**Мәктәпкәчә белем бирү мәгариф программасын гамәлгә ашыра торган белем бирү оешмасында баланы карау һәм тәрбияләү өчен гражданнарның ата-аналар түләвенә киткән чыгымнарының максималь мөмкин булган өлеше**

| Гаиләнең бер әгъзасына керем күләме | Гражданнарның ата-аналар түләвенә тотылган чыгымнарының максималь мөмкин булган өлеше, % | | |
|---|---|---|---|
| | 1 нче балага | 2 нче балага | 3 нче балага |
| 10 000 сумга кадәр | 60 | 38 | 23 |
| 10 001 сумнан 15 000 сумга кадәр | 70 | 43 | 36 |
| 15 001 сумнан 20 000 сумга кадәр | 80 | 53 | 53 |
| 20 000 сумнан артык | 100 | 100 | 100 |
| Яшәү минимумыннан азрак (күпбалалы гаилә өчен) | 0 | 0 | 0 |

## II. Компенсация билгеләү һәм түләү тәртибе

2.1. Компенсация алу өчен гариза бирүче Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе белән балалар бакчаларына йөрүче балалары булган гражданнарны кабул итү, консультацияләү, компенсация билгеләү (компенсация билгеләүдән баш тарту) турында карар кабул итү хезмәтләрен күрсәтүгә гражданлык-хокукый килешү төзегән махсуслаштырылган оешмага Татарстан Республикасы территориясендә яшәү урыны буенча (гариза бирүче яшәү урыны буенча теркәлмәгән очракта – тору урыны буенча), ә Татарстан Республикасы территориясендә теркәлмәгән гражданнар өчен – тиешле белем бирү оешмасының теркәлү урыны буенча түбәндәге документларны тапшыра:

1) компенсация билгеләү турында гариза;

2) кирәкле документлар белән компенсацияне билгеләү турында гариза тапшырылган айга кадәр килә торган 12 календарь ай эчендә гаиләнең һәр әгъзасының керемнәре турында документлар;

3) компенсация билгеләнә торган баланың туу турындагы таныклыгының күчермәсе (күчермә нотариуста расланмаган булса, төп нөсхәсен күрсәтеп);

4) гариза бирүче анасы/атасы (законлы вәкиле) булып торган башка балаларның тууы (уллыкка алынуы) турында таныклыкларының күчермәләре (күчермә нотариуста расланмаган булса, төп нөсхәсен күрсәтеп). Опекадагы балага компенсация билгеләү өчен өстәмә рәвештә балага опека билгеләнүе турында җирле үзидарә органнары карарыннан өземтә тапшырыла;

5) ышанычлы затлар өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә рәсмиләштерелгән ышанычнамәнең күчермәсе;

6) суд карары – ата-ананың берсе (ата-ана) балага (балаларга) карата ата-ана хокукыннан мәхрүм ителгән очракта;

7) баланы тиешле белем бирү оешмасына урнаштыру турындагы килешүнең күчермәсе;

8) белем бирү оешмасында баланы карау һәм тәрбияләү өчен түләү квитанциясенең күчермәсе яки, түләү квитанциясе булмаган очракта, баланың шәхси счет номеры;

9) гариза бирүченең гаилә әгъзаларыннан яисә аларның законлы вәкилләреннән гариза (ирекле рәвештә):

- аларның шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә ризалыгы булу;

- шәхси мәгълүматны органга яисә оешмага тапшырганда гариза бирүченең алар исеменнән эш итәргә вәкаләте.

Гариза бирүче гариза белән мөрәҗәгать иткәндә паспортын (аны алмаштыра торган документны), мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе белән килешү төзегән затның кредит оешмасындагы шәхси счетының номерын (компенсацияне банк аша алган очракта) күрсәтә.

Мөрәҗәгать иткән көнгә гариза бирүче гаиләнең җан башына уртача керемен исәпкә алып билгеләнгән компенсацияне алучы зат булып торса, гариза бирүче керемнәр турында мәгълүматлар тапшыру йөкләмәсеннән азат ителә.

Мөрәҗәгать иткән көнгә гариза бирүче мәктәпкәчә белем бирү мәгариф программасын гамәлгә ашыра торган белем бирү оешмасында баланы карау һәм тәрбияләү өчен ата-аналар түләвенең бер өлешенә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 гыйнварындагы 9 номерлы «Мәктәпкәчә белем бирү мәгариф программасын гамәлгә ашыра торган белем бирү оешмаларында баланы карау һәм тәрбияләү өчен ата-аналар түләвенең бер

өлешен компенсацияләү турында»гы карары белән билгеләнгән тәртиптә исәпләнгән компенсацияне алучы булып торса, ул әлеге Тәртипнең 2.1 пунктындагы 3-8 пунктчаларында күрсәтелгән мәгълүматларны тапшыру йөкләмәсеннән азат ителә.

2.2. Гариза һәм документлар почта аша җибәрелергә мөмкин. Гариза һәм документларны почта аша җибәрү балалар бакчаларына йөри торган балалары булган гражданнарны кабул итү, консультацияләү, компенсация билгеләү (компенсация билгеләүдән баш тарту) турында карар кабул итү хезмәтләрен күрсәтүгә килешү төзелгән махсус оешма тарафыннан алу очрагын һәм аларны алу көнен раслау мөмкинлеген бирә торган ысул белән гамәлгә ашырыла.

2.3. Әлеге тәртипнең 2.1 пунктында күрсәтелгән документлар нигезендә кабул итү, консультацияләү, балалар бакчаларына йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация билгеләү (компенсация билгеләүдән баш тарту) турында карар кабул итү хезмәтләрен күрсәтүгә килешү төзелгән махсуслаштырылган оешма гариза белән барлык кирәкле документлар теркәлгән көннән алып 10 көн эчендә компенсация билгеләү турында яки аны билгеләүдән баш тарту турында карар кабул итә һәм әлеге карарны гариза бирүче күрсәткән ысул белән (хат, СМС-хәбәр, электрон почта, ә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында теркәлгән гариза бирүчеләр өчен – шәхси кабинет аша хәбәр итеп) гариза бирүчегә җиткерә.

2.4. Компенсацияне билгеләүдән баш тарту өчен нигез булып түбәндәгеләр тора:

- әлеге тәртипнең 2.1 пунктында күрсәтелгән документларны тапшырмау;

- гамәлдә булу вакыты узган документлар тапшыру (күрсәтү);

- закон таләпләрен бозып рәсмиләштерелгән документлар тапшыру;

- Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурыч булу.

2.5. Компенсация гариза белән барлык кирәкле документлар тапшырылган айдан билгеләнә һәм алты ай дәвамында түләнә.

2.6. Балалар бакчаларына йөрүче балалары булган гражданнарга өстәмә компенсация алу хокукын яңадан рәсмиләштерү 2026 елның беренче өч аенда (гыйнвар, февраль, март), мөрәҗәгать иткән айга кадәр өстәмә компенсация түләүне туктатып тормыйча, вәкаләтле орган тарафыннан расланган график буенча гамәлгә ашырыла.

2.7. Махсус оешмага Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминиятләштерү фондыннан, шул исәптән ведомствоара электрон хезмәттәшлек бердәм системасыннан һәм аңа тоташтырыла торган ведомствоара мәгълүмати

хезмəттəшлекнең төбəк системаларыннан файдаланып, эш бирүче (иминиятлəштерүче зат) тарафыннан физик зат файдасына исəплəнгəн түлəүлəр һəм башка төрле бүлəклəү суммасы турында мəгълүматлар алу мөмкинлеген бирə торган мəгълүмати хезмəттəшлек итү башкарылганнан соң, компенсацияне билгелəү аның гаризада күрсəтелгəн ризалыгы белəн, Россия Федерациясе Пенсия һəм социаль иминиятлəштерү фондында компенсация билгелəү өчен гариза белəн мөрəҗəгать иткəн айдан алдагы 12 ай өчен булган мəгълүматлар нигезендə башкарыла.

2.8. Балалар бакчаларына йөрүче балалары булган гражданнарны кабул итү, консультациялəү, компенсация билгелəү (компенсация билгелəүдəн баш тарту) турында карар кабул итү хезмəтлəрен күрсəтүгə килешү төзелгəн махсус оешмада гражданинның компенсация алуга хокукы булуын раслый торган мəгълүматлар булган очракта, компенсация аңа, гражданин мөрəҗəгать итмичə генə, автомат рəвештə яңа вакытка билгелəнə.

## III. Йомгаклау нигезлəмəлəре

3.1. Гариза бирүче тапшырылган мəгълүматларның дөреслеге, шулай ук аларны үз эченə алган документларның чын булуы өчен җаваплы.

3.2. Балалар бакчаларына йөрүче балалары булган гражданнарны кабул итү, консультациялəү, компенсация билгелəү (компенсация билгелəүдəн баш тарту) турында карар кабул итү хезмəтлəрен күрсəтүгə килешү төзелгəн махсус оешма, документларның чын һəм тапшырылган мəгълүматларның дөрес булу-булмавында шик барлыкка килгəн очракларда, үзенə бирелгəн вəкалəтлəр чигендə гариза бирүче тарафыннан тапшырылган мəгълүматларны өстəмə рəвештə тикшерергə хокуклы.

3.3. Компенсация суммасы гариза бирүченең банк счетына күчерелə.

Сəламəтлеге, яше, җəяү яки транспорт белəн барып банкта счет ачу һəм аннан файдалану мөмкинлеге булмаган гариза бирүчегə компенсация түлəү (китерү) элемтə оешмалары аша яисə гамəлдəге законнарда билгелəнгəн тəртиптə тиешле килешүлəр (контрактлар) төзелгəн, акчалата түлəүлəрне китерү белəн шөгыльлəнə торган башка оешмалар аша башкарыла.

3.4. Компенсацияне банк счетларына күчерү һəм почта элемтəсе ярдəмендə яки гамəлдəге законнарда билгелəнгəн тəртиптə тиешле килешүлəр (контрактлар) төзелгəн, акчалата түлəүлəрне китереп бирүне гамəлгə ашыра торган башка оешмалар тарафыннан китереп бирү исəплəү ае дəвамында башкарыла.

3.5. Гражданнар компенсация түләүне туктата торган хәлләрнең башлануы (белем бирү оешмасын үзгәртү, ата-ана хокукыннан мәхрүм ителү, гариза бирүченең вафат булуы) турында, мондый хәлләр башланган вакыттан алып бер ай узганчы, балалар бакчаларына йөрүче балалары булган гражданнарны кабул итү, консультацияләү, компенсация билгеләү (компенсация билгеләүдән баш тарту) турында карар кабул итү хезмәтләрен күрсәтүгә килешү төзелгән махсус оешмага хәбәр итәргә тиеш.

3.6. Түләүне туктата торган хәлләр башланган очракта, мондый хәлләр башланган айдан соң килүче айдан башлап түләү туктатыла.

3.7. Өстәмә компенсация алу хокукына йогынты ясый торган белә торып дөрес булмаган мәгълүматлар язылган документлар тапшыру һәм мәгълүматларны яшерү нәтиҗәсендә артык түләнгән компенсация суммалары вәкаләтле органның казна счетына гариза бирүче тарафыннан ирекле рәвештә түләнелә, ә гариза бирүче баш тарткан очракта, Россия Федерациясе законнары нигезендә түләттерелә.

3.8. Вәкаләтле орган гаебе белән вакытында алынмаган компенсация узган вакыт өчен чикләнмәгән вакытта түләнә.

3.9. Гариза бирүче вафат булган очракта, исәпләнгән, ләкин исән чакта аңа түләнмәгән компенсация суммасы мирас составына кертелә һәм Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән гомуми нигезләрдә мирас итеп бирелә.

3.10. Компенсация бирү мәсьәләләре буенча бәхәсләр суд тәртибендә хәл ителә.